

Боек Ватан сугышындагы Жинvгэ 75 ел тулу унае белэн Россия кvлэмендэ байтак чаралар vтте һэм vтэчэк. Yткэннэре арасында, эчтэлекле чара буларак, Рузаевка районы татарларын, башка миллэт вэкиллэре белэн бергэ, хормэт иттелэр. Алар ел да бу датаны югары эзерлек белэн каршы алалар. Быел, барлыкка килгэн шартларда, район администрациясе Архивы хезмэткэрлэре инициативасы белэн, А.В.Ухтомский мэдэният Yзэге алдындагы мэйданда, тирэн эчтэлекле 25 стенд урнаштырганнар. Бу материалларнын тозvчесе - озак еллар Рузаевка районы администрациясендэге Архив бvлеге начальнигы булып тырышып хезмэт иткэн Наилэ Шагидулла кызы Чугунова һэм анын бvлеге хезмэткэрлэре. Стендларны Рузаевка районы житэкчесе В.Ю.Кормилицын ярдэмендэ эзерлэнде. Бу – Ватаныбыз килэчэге турында кайгырту, яшь буыннын ата-бабаларын, эби-бабайларын хормэтлэv.      Татарларыбыз турындагы мэгълvмат стендлары тvбэндэ. Менэ Безруков Мизам Исмэтула улына багышланган стенд. Ул 1910 елда Рузаевка районы Татар Пишлэсе авылында кvп балалы крестьян гаилэсендэ туган, диелгэн. Белем ала алмый, чонки ул иртэ хезмэт эшчэнлеген башлый: башта Мизам Исмэтула улы кулакларда эшли, э 14 яше тулгач, Коломна шэһэрендэге крахмал заводына эшкэ китэ.

1942 елда туган Татар Пишлэсенэ эйлэнеп кайта. «…По мобилизации Рузаевским ОРВК Мордовской АССР был призван 708 зенитный артполк 37 м/м.», - дип язылган архив тактасында. М.И.Безруков Боек Ватан сугышы елларында 708 зенит-артиллерия дивизиясе Н-ский зенит полкында хезмэт итэ. Сугышчан батырлыклары очен торле бvлэклэргэ лаек була.

Истэлек. Сугыштан бер кон. 16 апрель. М.И.Безруков Великая елгасы буенда фашистларнын ике «Юнкерс»ын бэрдерэ, э бу вакытка инде зенитчылар исэбендэ жимерелгэн оч дошман самолеты була. Жир осте дошманнары белэн сугышырга туры килгэч, зенитчылар турыдан-туры наводка белэн тере кочне һэм илбасарларнын техникасын юкка чыгарганнар. Жинvне сугыш кырында каршылый ул. СССР Югары Советы Президиумынын 22.9.1945 елгы Указы нигезендэ шул елнын 14 ноябрендэ демобилизациялэнэ.

1945-1947 елларда Рузаевка резерв объектында эшли. 1947-1974 елларда Рузаевка станциясенен гражданнар корылмаларынын 2нче дистанциясендэ хезмэт итэ. Эш вакытында vзен яхшы яктан гына кvрсэтэ, грамоталар белэн бvлэклэнэ. 1969 елда «Коммунистик хезмэт ударнигы» исемен ала.

Сугыштан кайткач, берничэ тапкыр, ветераннар Советы чакыруы буенча, 44 орденлы Кутузов дивизия ветераннары белэн Мэскэv шэһэрендэге очрашуга барган кеше ул. 1995 елнын 23 октябрендэ вафат була.

Икенче стендка якын килэбез. Каршыбызда Ибраһим Сэяр Улы Сайганов батыр.

Рузаевка районынын Татар Пишләсе авылында 1921 елда туган. 1940 елнын ноябрендә Мордовия АССР Рузаевка РВКсы белән хәрбиләр сафына алына. Боек Ватан сугышы башлана. Карельский фронтында сугыша. «Воевал в 176 стрелковой Мазурской Краснознаменной Ордена Суворова дивизии 52 стрелкового полка пулеметчиком», - диелгән тактасында. Ватаны очен батырларча корәшкән. Ике тапкыр яраланган. 2 дәрәжә Ватан сугышы ордены, «Батырлык очен» медале белән бvләкләнгән. Архив хезмәткәрләре анын турында мәгълумат туплауны дәвам итәләр.
Тагы бер истәлек: стендтан Исмаил Якуп улы Шарипов безне кvзәтә.
Ул 1924 елнын 21 январында Рузаевка районынын Урледим авылында туган. Болдово авылы урта мәктәбен тәмамлаган 17 яшьлек яшvсмерне, сугыш чорындагы кvп кенә малайларны кебек vк, укырга жибәрәләр. Кадрлар әзерләv курсын тәмамлап, сержант исемендә Шарипов Исмаил Якуп улы танкка каршы полк каршындагы элемтә бvлеге командиры вазыйфасын башкара. 1942 елнын октябрендә ук ул танкка каршы жинел артиллерия дивизионынын элемтә бvлекчәсе командирлары арасына керә. Исмаил Якуп улы Шарипов Ельцадан алып Варшавага кадәр барган сугышларда актив катнашкан, Днепр һәм Висла елгаларын кичкән. Батыр И.Я.Шарипов Кызыл Йолдыз ордены, 2нче дәрәжә Ватан сугышы ордены, сугышчан казанышлары очен медальләр һәм башкалары белән бvләкләнгән.
1945 елда Болдово авылына кайта. Сугыштан сон партиянен Болдово райкомы инструкторы булып эшли. Аннары 14 ел Рузаевка икмәк комбинаты директоры булып хезмәт итә.
Тагы бер хормәтле  фронтовик - Давлятша Джарулла улы Гурин. Д.Д.Гуриннын документлары (топ носхәсе һәм кvчермәләре) туганнары тарафыннан Рузаевка муниципаль районы администрациясенен Архив бvлегенә 2015 елнын 29 апрелендә тапшырылды. Документлар эшкәртелгән, системалаштырылган.
Давлятша Джарулла улы Гурин 1924 елнын 30 июнендә Рузаевка районы Татар Пишләсе авылында туа. 1940 елнын 23 июнендә туган авылы мәктәбен тәмамлаганнан сон, Мордовия Республикасы Татар Пишләсе авылынын «Кеч» колхозында эшли.
Давлятша Джарулла улы Гуриннын фронт юлы Курск дугасында башланган. Саранск пехота училищесын тәмамлаганнан сон, унтугыз яшьлек лейтенантны минометчиклар взводы командиры итеп билгелиләр, 1943 елнын июлендә Орелга һәм Белгородка ыргылып китvче немец «тигрлары», «фердинандлары» һәм аларнын артыннан дошман пехотасы белән капланган беренче сугышы була; жир, танклар, кешеләр яна. Һавада озлексез бәрелешләр бара, дошман һожvм итә, бертуктаусыз атудан коралларнын кәvсәләре ярыла, әмма Совет сугышчылары Боек Ватан сугышынын бу зур корәшендә немец-фашистларын тар-мар итә һәм беренче сугышчан бvләген - Кызыл Йолдыз орденын ала.
Аннары Днепрны форсировать итәләр. Минометчылар, елга аша кулдан ясалган плоталарда vтеп, шунда ук фашистларга каршы корәшәләр. Биредә Давлятша Джарулла улы Гуринга авыр яраланган рота командирын алыштырырга һәм минометчыларнын хәрби хәрәкәтләре белән житәкчелек итәргә туры килә. Бу сугышлардан сон II дәрәжә Ватан сугышы ордены белән бvләкләнә. Икенче шундый ук орден белән немец-фашист гаскәрләренен Курсунь-Шевченков округы группировкасын бетерv очен бvләкләнә. Беренче Украина фронтынын оченче гвардия армиясе белән Гурин Давлятша Джарулла улы бик кvп юллар vтте: Украина, Белоруссия, Польшанын ун як ярларын азат итvдә катнаша, Висла, Одер, Берлинны штурмлый. Ул сугышны Чехословакия башкаласы

Праганын 1нче Украина фронтынын азат ителгән гаскәрләре белән тәмамлый; миномет взводы командирыннан аерым дивизион командирына кадәр юлны уза. 1946 елда Д.Д.Гурин Совет Армиясе сафларыннан запаска китә һәм тыныч хезмәткә әйләнеп кайта.
Рузаевка тимер юлында башта станокчы булып эшли, аннары комсомол, партия эшендә була, ә партиянен Үзәк комитеты авыл хужалыгына эшкә жибәрv турында Карар кабул иткәч, Давлятша Джарулла улы авылга эшкә барырга теләк белдерә. 1955 елнын июлендә колхозчыларнын гомуми жыелышында Давлятша Джарулла улы Гурин Рузаевка районынын «Кеч» колхозы идарәсе председателе итеп сайлана. Шулай итеп, ул vзенен туган авылы Татар Пишләсенә кайта. Анда оч сугыш ветераны, берничә тапкыр яраланган әтисе дә, бабасы да, бабасынын бабасы да элек-электән жирдә хезмәт куйганнар һәм Д.Д.Гурин да тырышып эшли. Ул житәкләгән колхоз vсә, анын икътисадын ныгыта һәм анын белән бергә кешеләр дә vсә, белем, уртак эш язмышы очен жаваплылык та югарырак кvтәрелә. Дvрт баланын әтисе буларак, студент була һәм Мордовия дәvләт университетын тәмамлый; агроном дипломын ала. Мордовиядә беренчеләрдән булып колхозчылар хезмәтенә тvләv системасына кvчә, цех системасын кертә. Шулай итеп, колхоз оешуы бара.
Югары Совет Президиумынын 1971 ел нын 8 апрелендәге Указы белән Гурин Давлятша Джарулла улы Ленин ордены, Октябрь Революциясе ордены белән бvләкләнгән. 1977 елнын 1 ноябреннән Мордовия АССРнын атказанган агрономы дигән мактаулы исем бирелә. 1980 елнын 4 январыннан РСФСРнын атказанган агрономы дигән мактаулы исем бирелә,1984 елнын 6 июнендә Халыклар Дуслыгы ордены белән бvләкләнә.
1984 елда  Гурин Давлятша Джарулла улы Мордовия АССРнын Хезмәт батырлыгы һәм каһарманлыгы китабына кертелгән.
Батырларыбыз турында материалларны туплау Рузаевка районы адми нистрациясендәге Архив бvлеге начальнигы Наилә Шагидулла кызы Чугунова һәм бvлеге хезмәткәрләре дәвам итә. Хәтер – мәнгелек.

*Наилэ НАСЫРОВА*